**«РАСЛЫЙМ»**
**Татарстан Республикасы**
**мәгариф һәм фән министры**
**_______________И.Г.Һадиуллин**
**«19» ноябрь 2025 нче ел**

# Рус телендә белем бирү мәктәпләренең рус телле укучылары өчен 2026 нчы елда туган (татар) телдән дәүләт йомгаклау аттестациясен уздыру материалларының күрсәтмә варианты

# Демонстрационный вариант контрольных измерительных материалов для проведения в 2026 году государственной итоговой аттестации (ГИА) по родному (татарскому) языку для русскоязычных учащихся школ с русским языком обучения

разработан федеральным государственным автономным образовательным учреждением высшего образования
«КАЗАНСКИЙ (ПРИВОЛЖСКИЙ) ФЕДЕРАЛЬНЫЙ УНИВЕРСИТЕТ»

подготовлен государственным бюджетным учреждением
«РЕСПУБЛИКАНСКИЙ ЦЕНТР МОНИТОРИНГА КАЧЕСТВА ОБРАЗОВАНИЯ»

утвержден МИНИСТЕРСТВОМ ОБРАЗОВАНИЯ И НАУКИ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

## Эшне башкару өчен күрсәтмә

Татар теленнән төп дәүләт имтиханын тапшыру өчен, 3 сәгать 55 минут (235 минут) вакыт бирелә. Имтихан эше **21 биремне** үз эченә алган **4** бүлектән тора. **1 нче бүлектәге** 8 бирем (1 – 8 нче биремнәр) укучыларның тыңлап аңлау күнекмәләрен тикшерүгә юнәлтелгән. **2 нче бүлектәге** 4 бирем (9 – 12 нче биремнәр) укучыларның уку күнекмәләрен тикшерү максатыннан бирелә. **3 нче бүлектәге** 6 бирем (13 – 18 нче биремнәр) укучыларның лексик-грамматик күнекмәләрен тикшерүгә кайтып кала. **4 нче бүлектәге** 19 – 20 нче биремнәр сөйләм ситуациясенә караган татарча репликалар язуны күздә тота. Ачык типтагы **21 нче бирем** укучыларның язма сөйләмен тикшерүгә юнәлдерелгән.

.

**Уңышлар телибез!**

## Инструкция по выполнению работы

Время, отведенное на выполнение заданий – 3 часа 55 минут (235 минут). Экзаменационная работа по татарскому языку состоит из четырех разделов, включающих 21 задание.

**Раздел 1** (задания по аудированию) включает 8 заданий на понимание аутентичных текстов (задания 1 - 8). **Раздел 2** (задания по чтению) включает в себя 4 задания (задания 9 - 12). **Раздел 3** (задания по лексике и грамматике) состоит из 6 заданий (задания 13 - 18). **Раздел 4** (задания по письменной речи) состоит из 2 заданий на написание реплик по предложенной коммуникативной ситуации (задания 19 – 20) и задания, в котором предлагается написать личное письмо (задание 21).

**Желаем успеха!**

## Раздел 1

***Прослушайте 4 коротких диалога. В заданиях 1 - 4 укажите правильный вариант ответа. Вы услышите аудиозапись дважды.***

**1** **Дусларга кайсы транспорт төре ошый?**
1) автобус
2) автобус та, троллейбус та
3) троллейбус

**2** **Айсылу Рәшитне кая чакыра?**
1) ярышка
2) саф һавада йөрергә
3) шугалакта шуарга

**3** **Айсылу нәрсә сатып алган?**
1) дәреслек
2) сүзлек
3) эш дәфтәре

**4** **Рәшит кайсы порталдан күбрәк файдалана?**
1) Татарстан китап нәшрияты порталыннан
2) КФУ порталыннан
3) Татар энциклопедиясе институты порталыннан

***Прослушайте разговор двух друзей. Определите, какие из приведенных утверждений 5 - 8 соответствуют содержанию текста (1), а какие – не соответствуют (2). Вы услышите аудиозапись дважды.***

**5** Дуслар татар ашлары турында сөйләшәләр.
1) текстка туры килә 2) текстка туры килми

**6** Самат салатлар ясарга ярата.
1) текстка туры килә 2) текстка туры килми

**7** Алсуның яраткан милли ризыгы - бәлеш.
1) текстка туры килә 2) текстка туры килми

**8** Алсу Саматны яңа салат белән сыйларга сүз бирә.
1) текстка туры килә 2) текстка туры килми

## Раздел 2

***Прочитайте текст. В заданиях 9 - 12 укажите правильный вариант ответа.***

### Ике тамчы

Зур бер агачның яфрагы өстендә ике тамчы сөйләшеп утыра:

— Кояш чыгып кыздыра башласа, безгә бик кыен булачак! — ди беренче тамчы.

— Икәү бергә кушылыйк та, җиргә сикереп төшик! — ди икенчесе.— Җирдә берни дә юкка чыкмый.

Шуннан алар икәү, кулга-кул тотынышып, яфрактан ботакка, ботактан җиргә сикереп төшкәннәр. Алар шундый кызу төшкәннәр, хәтта җирне тишеп, бик еракка җиткәннәр. Шуннан алар җир астындагы су патшалыгына килеп чыкканнар. Монда бөтен дөнья тыныч икән: кошлар да сайрамый, урман да шауламый. Тамчыларга күңелсез булып киткән.

— Юк,— дигән беренче тамчы,— мондагы тормыш миңа ошамый. Минем җир өстеннән челтер-челтер агасым, дулкыннарга кушылып чабасым килә.

— Ә моннан, җир астыннан ничек чыгабыз?—дигән икенче тамчы.

— Бергәләшеп тырышсак, җиңәрбез, җир өстенә чыгарбыз,— дигән беренче тамчы.

Шуннан алар тагын кулга-кул тотышканнар, үзләре кебек кыю тамчыларны ияртκәннәр дә ташлар арасыннан кысыла-кысыла алга киткәннәр. Шул рәвешле, алар, караңгы җир астында юл ярып, көннәр, атналар, айлар буе барганнар. Ниһаять, бер калын тауны тишеп, җир өстенә килеп чыкканнар. Аннары сөенә-сөенә алга чапканнар. Бара торгач, зур елгага килеп кушылганнар. Тамчыларның көчләре арткан. Алар теләкләренә ирешкәннәр: елгада турбиналарны әйләндергәннәр, йортларны яктыртканнар. Аннары тагын алга киткәннәр — зур диңгезгә барып кушылганнар.Тырыш тамчылар күп нәрсә күргәннәр, күп дуслар тапканнар, күп эшләр эшләгәннәр, кешеләргә күп ярдәм иткәннәр.

(*Фәнис Яруллин).*

**9** Тамчылар ни өчен җиргә төшәргә уйлаганнар?
1) Җирне тишәргә уйлаганнар.
2) Кояш кыздырудан курыкканнар.
3) Агач яфрагында аларга күңелле булмаган.

**10** Су патшалыгында тормыш нинди?
1) Анда кошлар сайрый.
2) Анда күңелсез икән.
3) Анда урман шаулый.
4) Анда күңелле түгел икән.

**11** Тамчылар җир астыннан ничек чыканнар?
1) Ташларны тишеп чыканнар.
2) Юл ярып чыканнар.
3) Тауны тишеп чыканнар.
4) Кыю тамчыларны ияртеп чыкканнар.

**12** Җир өстендә тамчылар нишләгәннәр?
1) Теләкләренә ирешкәннәр.
2) Максатларын билгеләгәннәр.
3) Күп нәрсә күргәннәр.
4) Кешеләргә файда китергәннәр.

## Раздел 3

***Прочитайте текст. В заданиях 13 – 18 определите правильный вариант ответа.***

Икмәкне кемнәр пешерә?

Кызыксынсагыз, әйдәгез безнең белән — күмәч-кондитер (13) ... киттек. Ни өчен нәкъ шундамы? Үз күзләребез белән күрик әле.

Әһә... Биналар иркен, чиста, якты икән. Әчкелт ис таралган, (14) ...? Юк, бу әле ипи исе түгел. Ул ис камыр әчетү (15) ... килә. Менә камыр торба (16) ... бүлү машиналарына төшә. 850 граммлы ипи алу (17) ..., 950 грамм камыр бүленә. Камыр кисәкләрен тәгәрәтә торган машиналар формаларга төшерә. Формалар төрле: түгәрәк, овал, дүртпочмаклы. Формаларга салынган камыр соңрак шкафларда 40—45 минут кабара һәм шуннан соң гына мичкә керә.

Карагыз, мичтән нинди хуш исле ипиләр чыга! Аларны киштәләргә тезәләр. Кызык инде. Биредә ипи пешерүгә кеше кулы тими кебек. (18) .... машиналар башкара. Шулай да... «Ипинең тәме пешерүчегә бәйле,— ди технолог.

**13** 1) комбинатка 2) комбинатына 3) комбинатта 4) комбинаты

**14** 1) дисез 2) дисезме 3) дидегез 4) ди

**15** 1) савытларыннан 2) савытларына 3) савытларында 4) савыты

**16** 1) турында 2) белән 3) аша 4) икән

**17** 1) саен 2) өчен 3) кебек 4) турында

**18** 1) барысын 2) һәрберсен 3) тулы 4) барлык

## Раздел 4

***В заданиях 19-20 необходимо написать реплики в соответствии с заданной речевой ситуацией.***

**Сөйләм ситуациясенә туры килгән репликаларны языгыз.**

**19** Сообщите друзьям, что вам нравятся стихи Равиля Файзуллина.

**20** Спросите у друга (подруги), куда он (она) хочет поехать в летние каникулы.

**21** **Вы получили письмо от друга (подруги). Напишите ему (ей) письмо объемом не менее 60 слов, ответив на его (её) вопросы.**
**Для ответа на это задание используйте специальный бланк ответов.**

*... Безнең мәктәптә очрашулар еш була. Соңгы тапкыр без танылган спортчы Данис Зарипов белән очраштык. Данис абый безгә хоккейга килүе турында сөйләде, яхшы хоккейчы булу серләрен ачты. Без Данис абыйдан автограф та алдык, аның белән фотога да төштек.*

*... Ә сезнең мәктәптә нинди очрашулар үткәрелә?... Бу чараларда син нишлисең? ... Син кем белән очрашу үткәрүләрен теләр идең, ни өчен?*

## Тыңлап аңлау биремнәре өчен текстлар

**Прослушайте 4 коротких диалогов. В заданиях 1 - 4 укажите правильный вариант ответа. Вы услышите аудиозапись дважды.**

**Беренче сорау. Дусларга кайсы транспорт төре ошый?**
**Айсылу:** Сәлам, Рәшит!
**Рәшит**: Хәерле көн, Айсылу! Дәресләр бетүгә, мин сине мәктәп янында көтәрмен. Кичә сөйләшкәнчә, бергә Милли китапханәгә барырбыз.
**Айсылу**: Яхшы. Синеңчә, кайсы транспорт уңайлырак булыр? Троллейбусмы? Автобусмы?
**Рәшит**: Нәрсә килә, шуңа утырырбыз. Минемчә, икесе дә уңайлы.
**Айсылу**: Кайсы тукталышка кадәр барырга кирәк?
**Рәшит**: Ирек мәйданы тукталышында төшәбез, аннары берничә минут җәяү барабыз.
**Айсылу:** Әйе, мин бераз хәтерлим. Бер тапкыр бу китапханәдә булдым.
**Рәшит:** Хәзер шәһәр транспорты яхшы йөри. Бик тиз барып җитәрбез дип уйлыйм.
**[2 секунд пауза]**
**Прослушайте диалог второй раз.**
[язма икенче тапкыр яңгырый]
**[2 секунд пауза]**

**Икенче сорау. Айсылу Рәшитне кая чакыра?**
**Рәшит:** Айсылу, быел нинди түгәрәкләргә йөрисең?
**Айсылу**: Вакыт бик тыгыз булса да, “Апуш” театр студиясендә шөгыльләнүемне дәвам итәм.
**Рәшит:** Әйе, быел безнең өчен бик җаваплы ел. Шулай да мин көрәш белән шөгыльләнүемне дәвам итәргә телим.
**Айсылу:** Кайсы көннәрне тренировкага йөрисең?
**Рәшит:** Сишәмбе һәм пәнҗешәмбе көннәрне 16.00 сәгатьтән 19.00 сәгатькә кадәр. Ә син кайсы көннәрне студиядә шөгыльләнәсең?
**Айсылу:** Безнең дәресләребез чәршәмбе һәм җомга көннәрне була. Гадәттә без анда ике сәгать шөгыльләнәбез. Ләкин кайбер көннәрне дәресләр озаграк та булырга мөмкин, бигрәк тә премьера алдыннан.
**Рәшит:** Шулай, ярышлар алдыннан безне дә тренерыбыз озаграк тота.
**Айсылу:** Әйдә, ял көнне бергә шугалакка барабыз. Саф һавада булырбыз.
**Рәшит**: Ярар, мин риза!
**[2 секунд пауза]**
**Прослушайте диалог второй раз.**
[язма икенче тапкыр яңгырый] **[2 секунд пауза]**

**Өченче сорау. Айсылу нәрсә сатып алган?**
**Рәшит:** Айсылу, әйт әле, кичә син кибеткә бардың. Нәрсәләр алырга кирәк иде?
**Айсылу:** Минем үземә һәм сеңлемә уку әсбаплары аласым бар иде, шуңа күрә дәресләрдән соң кибеткә киттем.

**Рәшит:** Кайсы кибеткә бардың?
**Айсылу:** Бауман урамындагы татар китаплары кибетенә.
**Рәшит:** Кирәкле әйберләрне алдыңмы?
**Айсылу:** Әйе, үзем өчен татар теленең аңлатмалы сүзлеген алдым, ә сеңлемә дәфтәрләр, бетергеч һәм төсле карандашлар алдым. Ул бишенче сыйныфта укый.
**Рәшит:** Әйбәт булган.
**[2 секунд пауза]**
**Прослушайте диалог второй раз.**
[язма икенче тапкыр яңгырый]
**[2 секунд пауза]**

**Дүртенче сорау. Рәшит кайсы белем бирү порталыннан күбрәк файдалана?**
**Рәшит:** Айсылу, әйт әле, татар теленнән һәм әдәбияттан дәресләргә әзерләнгәндә, синниди чаралар кулланасың?
**Айсылу:** Гадәттә, мин сүзлекләр, хрестоматияләр кулланам. Ә син үзең нәрсәләрдән файдаланасың?
**Рәшит:** Мин күбрәк электрон ресурслардан файдаланам. Хәзерге вакытта татар телендә белем бирү порталллары уңышлы эшли. Аларда төрле өлкәләргә караган мәгълүматны табып була.
**Айсылу:** Мин никтер китапларны карарга, алардан кирәкле әйберләрне эзләргә яратам.
**Рәшит:** Дөрес, алар да ярдәмгә килә. Ләкин Интернеттан текстларны күчереп алып куярга мөмкин, җыеп утырырга кирәк түгел.
**Айсылу:** Килешәм. Ә сиңа кайсы портал күбрәк ошый?
**Рәшит:** Мин Татарстан фәннәр академиясе порталындагы сүзлекләрдән киң файдаланам, Татарстан китап нәшриятының порталын кулланам, ә иң ошаганы – Татар энциклопедиясе институты порталы. Анда татар халкының күренекле шәхесләре турында бик кызык материал урнаштырылган.
**Айсылу:** Рәхмәт сиңа яңалыклар өчен!
**[2 секунд пауза]**
**Прослушайте диалог второй раз.**
[язма икенче тапкыр яңгырый]
**[2 секунд пауза]**

***Прослушайте разговор двух друзей. Определите, какие из приведенных утверждений 5 - 8 соответствуют содержанию текста, а какие – не соответствуют. Вы услышите аудиозапись дважды.***

**[пауза 20 секунд]**

Самат: Сәлам, Алсу!
Алсу: Сәлам, Самат!
Самат: Алсу, сиңа кайсы татар милли ризыгы күбрәк ошый?

Алсу: Татар ризыкларының барысы да бик тәмле. Шулай да, минемчә, иң тәмлесе – өлеш.
Самат: Ә мин бәлеш яратам. Әнием бик тәмле пешерә. Бәйрәм җитсә, без барыбыз да әнидән бәлеш пешерергә сорыйбыз. Аның бәлешләре телеңне йотарлык була.
Алсу: Ә син үзең нәрсә пешерә аласың?
Самат: Мин бәрәңге кыздырырга яратам. Аның исе шундый тәмле була! Мин кыздырган бәрәңге һәрвакыт кетердәп тора. Безнең гаиләдә барысы да бу ризыкны ярата.
Алсу: Ә мин салатлар ясарга яратам.
Самат: Нинди салат? Яшелчә салатымы? Ит салатымы?
Алсу: Без әнием белән төрле-төрле салатлар ясыйбыз.
Самат: Рецептларын каян аласың?
Алсу: Интернеттан да карыйм, дус кызларымнан да сорыйм. Кайвакыт без үзебез дә яңа рецепт уйлап табабыз, эксперимент үткәрәбез.
Самат: Кызык! Син уйлап тапкан салатны минем дә ашап карыйсым килә.
Алсу: Туган көнемдә яңа салат ясармын, шунда авыз итәрсең. Ошаса, сине дә өйрәтермен.
Самат: Кунаклар өчен бәйрәм табыны әзерләү бик җаваплы эш дип саныйм, чөнки кемдер яшелчә ризыкларын ашарга ярата, кемгәдер ит күбрәк кирәк.
Алсу: Шулай, табын әзерләүдә дә иҗадилык кирәк. Әзерләгән ризыкларны матур итеп урнаштыру да осталык таләп итә.
Самат: Әйе, бик дөрес.
Алсу: Бәйрәмнәрдә мин табын әзерләргә яратам. Әнием мине һәрвакыт мактый, рәхмәтле була.
Самат: Минем андый осталыгым юк. Әниемә булышам гына.
Алсу: Шунысы да бик кирәкле эш.
Самат: Әйе, әнием дә шулай ди.
Алсу: Ярдәмчел булу – бик яхшы сыйфат.
**[2 секунд пауза]**
**Прослушайте диалог второй раз.**
[язма икенче тапкыр яңгырый]
**[2 секунд пауза]**

# ОТВЕТЫ
# ҖАВАПЛАР

| **Биремнең номеры** | **Дөрес җавап** |
|---|---|
| 1 | 2 |
| 2 | 3 |
| 3 | 2 |
| 4 | 3 |
| 5 | 1 |
| 6 | 2 |
| 7 | 2 |
| 8 | 1 |
| 9 | 1 |
| 10 | 24/42 |
| 11 | 34/43 |
| 12 | 14/41 |
| 13 | 2 |
| 14 | 2 |
| 15 | 1 |
| 16 | 3 |
| 17 | 2 |
| 18 | 1 |

## Татар теленнән имтихан эшен бәяләү системасы

1-18 биремнәрдә дөрес күрсәтелгән һәр җавап 1 балл белән бәяләнә. 10-12нче биремнәрдә 2 дөрес җавап бирелгән очракта гына 1 балл куела. Җаваплар биремнәрне үтәү күрсәтмәсендәгечә язылган булса һәм дөрес җавап үрнәге белән тулысынча туры килсә, бирем дөрес үтәлгән дип санала. 10-12 нче биремнәрдәге җавапта символларның эзлеклелеге мәҗбүри түгел.

## 19-20 нче биремнәрне бәяләү критерийлары

Сөйләм ситуациясенә караган репликалар язу. 19-20 нче биремнәр максималь 2 балл белән бәяләнә.

*1 нче таблица*

| *№* | *Бәяләү критерийлары* | *Баллар* |
|---|---|---|
| *I* | *Язылган текстның эчтәлеге* | |
| К1 | Сөйләм ситуациясенә караган репликаны формалаштыру | |

| | | |
|---|---|---|
| | Имтихан бирүче, сөйләм ситуациясенә караган репликаны аңлап, җавабын дөрес формалаштырган. Коммуникатив бурыч төгәл үтәлгән.<br>Фактик хаталар юк. | 1 |
| | Имтихан бирүче сөйләм ситуациясенә караган репликаны дөрес формалаштырмаган.<br>***Яки*** Сөйләм ситуациясенә караган реплика өлешчә генә формалаштырылган<br>***Яки*** дөрес формалаштырмаган.<br>***Яки*** Фактик хаталар бар.<br>***Яки*** Имтихан **бирүче башка сөйләм ситуациясенә караган реплика язган**. | 0 |
| *II* | *Грамоталылык* | |
| К2 | Орфография һәм сөйләм нормаларының үтәлеше | |
| | Репликада орфографиягә тел нормаларының үтәлешенә караган (грамматик, орфографик, стилистик, пунктуацион) хаталар юк.<br>***Һәм/ яки*** төрле нормаларга караган 2 хата бар. | 1 |
| | Репликада тел нормаларының үтәлешенә караган 3 яки күбрәк хата бар.<br>***Яки*** Имтихан **бирүче башка сөйләм ситуациясенә караган реплика язган**. | 0 |
| Язма эш өчен максималь балл | | 2 |

**21 нче биремне бәяләү критерийлары**

**Шәхси хат язу биремен бәяләү критерийлары**

*2 нче таблица*

| К | Бәяләү критерий лары | 3 балл | 2 балл | 1 балл | 0 балл |
|---|---|---|---|---|---|
| К1 | Коммуни катив бурычны үтәү | ***Эш тулысынча башкарылган:*** 3 сорауга да тулы җавап бирелгән. Мөрәҗәгать итү, исәнләшү, | ***Эш башкарылган:*** 3 сорауга да җавап бирелгән, әмма берсенә бирелгән җавап тулы түгел. Хат | ***Эш өлешчә башкарылган***: 2 сорауга гомуми җавап бирелгән, әмма 1 сорауга бирелгән | ***Эш башкарыл маган:*** 2 сорауга җавап бирелмәгән ***яки*** текстның |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| | | саубуллашу һәм имзалау фразалары дөрес сайланган. Алынган хатка рәхмәт белдерелгән | стилен бозган 1-2 төгәлсезлек бар ***һәм/яки*** алынган хатка рәхмәт белдерелмәгән | җавап тулы түгел ***яки*** бер сорауга гомумән җавап юк. Хат стилен бозган 3 яки күбрәк төгәлсезлек бар, итагатьлелек формалары сакланмаган | күләме тулмый |
| К2 | Текстны оештыру | | Текст логик эзлеклелектә төзелгән һәм абзацларга бүленештә хаталар юк; тел чаралары дөрес кулланылган; хатның төзелеше язма этикет нормаларына туры килә | Текст, гомумән алганда, логик эзлеклелектә төзелгән, ләкин логик бәйләнешләрдә ***һәм /яки*** абзацларга бүленештә ***яки*** хатның төзелешендә 1-2 төгәлсезлек бар | Текст төзелешендә логик эзлеклелек сакланма-ган; язма текст төзелешен-дә 3 яки күбрәк хата бар, ***яки*** хатның төзелеше язма этикет нормалары-на туры килми. |
| К3 | Текстның лексик-грамма-тик төзелеше | Коммуникатив бурычны үтәү өчен кирәк булган төрле лексик һәм грамматик чаралар файдаланылган (текстны аңлауга зыян китермәгән 1-2 | Текстны аңлауга зыян китермәгән тел чараларына караган хаталар бар (3-4 тупас булмаган хата рөхсәт ителә) ***яки*** тел хаталары юк, ләкин артык гади лексик | Текстны аңлауга зыян китермәгән тел чараларына караган хаталар бар (5-6 тупас булмаган хата рөхсәт ителә) ***һәм /яки*** текстны | Текстны аңлауга зыян китерә торган хаталар 6 дан күбрәк |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| | | төгәлсезлек рөхсәт ителә) | һәм грамматик чаралар кулланылган | аңлауга зыян китерә торган 1-2 грамматик хата бар | |
| К4 | Орфография һәм пунктуа-ция | | Орфографик һәм пунктуацион хаталар юк, **яки** текст эчтәлеген аңлауга зыян китерми торган 1-2 хата бар | Текст эчтәлеген аңлауга зыян китерми торган 3-4 орфографик һәм пунктуацион хата бар | Текст эчтәлеген аңлауга зыян китерә торган орфографик һәм пунктуаци-он хаталар 4 тән күбрәк |

Шәхси хат язу биреме К1-К4 критерийлары буенча тикшерелә. Максималь **10 балл** алырга мөмкин.

Текстның эчтәлеге биремгә туры килмәсә (язма хат характерында булмаса, **тәкъдим ителгән сорауларга җавап урынына башка мәгълүмат язылса**, тәкъдим ителгән хат күчереп кенә язылса) бу бирем өчен 0 балл куела.

Хатның күләме **30** сүздән ким булса, К3 һәм К4 критерийлары буенча максималь балл куелмый.

Эшнең күләмен билгеләгәндә, беренче сүздән алып соңгысына кадәр (шулай ук адрес, язылу вакыты, имза да) исәпкә алына. **Хатта укучы үзенең чын исемен, адресын күрсәткән очракта эш тикшерелми.**

**Имтихан эше өчен түбәндәге билгеләр куела:**

0 - 15 балл – «2» ле билгесе;

16 - 21 балл – «3» ле билгесе;

22 - 27 балл – «4» ле билгесе. Искәрмә: бу очракта укучының тыңлап аңлау биремнәре өчен (1-8 нче биремнәр) баллары 4 дән кимрәк булмаска тиеш. Әгәр укучының тыңлап аңлау биремнәре өчен баллары 4 дән кимрәк булса, «3» ле билгесе куела.

28 - 32 балл – «5» ле билгесе. Искәрмә: бу очракта укучының язма сөйләм биремнәре өчен баллары 5 тән кимрәк булмаска тиеш. Әгәр укучының язма сөйләм биремнәре өчен баллары 5 тән кимрәк булса, «4» ле билгесе куела.